**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлегенең Гөлек торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

26 ноябрь 2025 ел № 2

2025 елның 20 мартында кабул ителгән № 33-ФЗ «Бердәм җәмгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Федераль законының 45, 69 маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлегенең Гөлек авылында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2026 елда Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлегенең Гөлек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә укучы студентлар, СВОда катнашучы гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары, СВОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Гөлек авылындагы гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Молодежная урамындагы юлны ремонтлау (вак таш сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) Гөлек торак пунктында традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (зират территориясен коймалау өчен төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Урыс авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Минзәлә муниципаль районының http://menzelinsk/tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Урыс авыл җирлеге башлыгы И.С. Аксюкова